ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

27 сентября 2017 г.

**КАРАР**

№ 5760

Башкарма комитетның 2015 елның
24 декабрендәге 7379 нчы карары белән
расланган капиталь төзелеш объекты
булмаган законсыз урнаштырылган
объектларны ачыклау, демонтажлау,
күчерү һәм саклау тәртибе турында
нигезнамәгә үзгәрешләр
кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пунктына туры китереп

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 нчы карары белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезнамәгә (Башкарма комитетның 2016 елның 9 февралендәге 6589 нчы, 2017 елның 9 июнендәге 3530 нчы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге нигезнамә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының, аның структур бүлекчәләренең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участокларындагы, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларындагы, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларындагы капиталь төзелеш объектлары булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклауга бәйле чараларны гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген регламентлаштыра»;

2) 3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектлар – капиталь төзелеш объекты булмаган объектлар, шул исәптән

муниципаль милектәге биналарда, төзелешләрдә, корылмалардагы киртәләп торучы җайланмалар (капкалар, калиткалар, шлагбаумнар, шул исәптән автоматик һәм декоратив киртәләр (коймалар), стационар булмаган сәүдә объектлары (барлык төр киосклар, павильоннар, прицеплар (тонарлар); лотоклар, палаткалар һәм тиз бозыла торган продукцияне һәм эчемлекләрне саклау һәм сату өчен суыткыч җиһазлар; шулай ук капиталь булмаган корылма итеп җиһазландырылган, шулай ук стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагында урнаштырылган җәмәгать туклануы объектлары (кафетерийлар, закусочныйлар һәм башка җәмәгать туклануы нокталары), Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участокларында, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир уастокларында муниципаль норматив хокукый актларга туры китереп рәсмиләштерелгән һәм әлеге объектларны урнаштыру өчен нигез булып торучы документлардан башка, яисә әлеге объектларны урнаштыру өчен нигез булып торучы документларның гамәлдә булу срогы чыкканнан соң урнаштырылган сәүдә автоматлары һәм металл контейнерлар»;

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның районнар Хакимияте Башлыклары И.Н. Галимовка, А.И. Кисловка, Р.М. Усмановага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин